Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Мамык авыл җирлеге
Мамык авылы торак пунктында гражданнар җыены
КАРАРЫ

«22» ноябрь 2020 ел № 4

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Мамык авыл җирлеге Мамык авылы торак пункты гражданнары җыены

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Мамык авыл җирлеге территориясендә яшәүче һәр балигъ булган кешедән, 1 гр инвалидлардан, балачак инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол калган хатыннарыннан, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан, яшәү урыны буенча теркәлгән, әмма яшәмәгән гражданнарнардан тыш, 2020 елда 1000 сум күләмендә үзара салым кертергә һәм җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

- Торак пункт чикләрендәге юлларны ремонтлау һәм карап тоту, асфальт юлның чокырларын ямау, юл кырыйларына бут ташы, ватык кирпеч, грунт, вак таш, ком түшәү (сатып алу, ташу, җәю)
Мамык авылы.
- Су белән тәэмин итү чыганакларына норматив таләпләрне тәэмин итү буенча эшләр үткәрү;
- Урамнарны яктыртуны оештыруны тәэмин итү өчен эшләр һәм хезмәтләр, товарлар сатып алу;
- Мамык авылында ике җәяүлеләр күперен ремонтлау (өслеген алыштыру, буяу, материал сатып алу);
- Мамык авылында "Җиңү" паркын төзекләндерү (Бөек Ватан сугышында катнашучыларга куелган һәйкәл каршында брусчатка сатып алу һәм урнаштыру, койманы ремонтлау).

Халык җыенында рәислек итүче: В.В. Рыжков

Мамык авыл җирлеге башлыгы В.В. Рыжков